Быел яз иртә килде. Март ахырында кыр эшләренен башлануын кvзәттек. Игенчеләр басуга ныклап әзерләнгәннәр: техника, орлыклар, ашламалар, механизаторлар – барысы да бvген мобилизацияләнгән. Әмма яз башы vзенен карлары-бозлары белән бераз эшне дә туктатып торды һәм кояш елмая башлауга иген кырлары янадан я ашлама, я орлык тутырган тракторлар, машиналар белән тулды.

Ләмберә районы «Нива» хужалыгы басуында кояшлы һава игенчеләрнен нәтижәле хезмәткә кәеф жылылыгын ныгыта. Биредәге игенчеләрнен югары уныш алу тәжрибәсе зур. Мәсәлән, узган ел һәр гектардан, кукуруз ашлыгын исәпкә алып, 50 центнерга якын уныш жыйган иделәр.

- Быел да vткән ел кvләмендә ашлык алырга ниятлибез, - ди «Нива» хужалыгы агрономы Сергей Тимофеевич Вильдякскин,- менә туфрак та дымланды; жылы коннәр котәбез. Кагыйдә буларак, чәчvдә тәжрибәле механизаторлар эшли. Бу сезон да шулай. Чәчv агрегатын егерме еллык стажы булган механизатор Рәшит Рәсим улы Кадеркаев житәкли. Кин колачлы чәчкечтә Петр Николаевич Попов vз вахтасын алып бара. Басуга орлык материалын шофер Аллям Исхак улы Бикбаев ташый. Тырышлыкнын нәтижәлелеге әлегә зур булмаган коллективнын койле гамәлләреннән тора.

Тырыш Рәсим Ариков культивация ысулы белән чәчv очен туфрак әзерли. Эш культивация белән чәчv арасында вакытлыча аермага юл куймас очен оештырылган. Шулай итеп, туфракта дым запасы кvпкә рациональрәк саклана.

- Язгы чәчvдә эш шактый кvп, - дип дәвам итә Сергей Тимофеевич Вильдякс кин ситуацияне анализлап. - 1050 гектарда арпа орлыгын чәчәргә исәп, яшел борчакка - 300 гектар, рапска - 100, силоска кукуруз - 400 гектар, бортеккә - 200 гектар мәйдан билгеләнгән. Иртә олгерә торган бортеклеләрне берничә атна эчендә чәчеп бетерергә

планлаштыра быз. «Нива» хужалыгы югары уныш алу эшендә кvптәнге традициягә ия. - Элекке житәкчебез В.В.Тулаев каршында ук без гектарыннан 50 центнер бортеклеләр унышы алдык, дип искә ала механизатор Рәшит Рәсим улы Кадеркаев, - бvгенге техника белән берничек тә тvбәнрәк уныш алырга ярамый.

Монын очен хужалыкта тәвәккәл адымнар ясала. 2900 гектар мәйданда дым каплатылды, 150шәр килограмм минераль ашлама кертелде, шытымнарны тукландыру каралган. Барлык агрочаралар да кыска вакыт эчендә һәм сыйфатлы итеп башкарылды. Болар барысы да киләчәкнен нигезе булып тора.

Н.ХӘЛИЛ